ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге составына керүче Чаксы торак пунктында 2023 елга үзарасалым кертү турында

№ 5 12 октябрь 2022 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчыстатьялары, «Татарстан Республикасындаҗирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нчестатьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлегенең Чаксы торак пунктында узган гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлегенең Тауиле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2023 елда 500(биш йөз) сум күләмендә үзарасалым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- урам яктырту лампаларын сатып алу һәм урнаштыру
- Чаксы авыл клубы бинасын агымдагы ремонтлау, килешү буенча эшләрне түләү
- Чаксы торак пунктындагы кардан юлларны чистарту

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Тауиле авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе В.И.Иванов